№3, Ноябрь 2025

# Чишмә башы

## МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”

**Бу санда**

***28 ноябрь*** - *Әниләр көне*
***4 ноябрь*** - *Халыклар бердәмлеге көне*
*Ял сәгатьләрендә*

**Әниләр турында мәкальләр һәм әйтемнәр!**



- ***Яктылык — кояш янында, яхшылык — әни янында.***
- ***Ана йөрәге — бала өчен дәрья.***
- ***Ана балага авызыннан өзеп каптыра.***
- ***Кояш янында — җылылык, ана янында — изгелек.***
- ***Ананың сөте бал, баланың теле бал.***

**Әниләр көне кайчан билгеләп үтелә башлый?**

*Әниләр көне – Россиядә ноябрь аеның соңгы якшәмбесе көнне билгеләп үтелә. Бу көнне барлык әниләрне һәм йөкле хатыннарны тәбрик итү күркәм традициягә әйләнде.Энилэр коне кайчан бәйрәм көн итеп билгеләнгән соң? Моның тарихы болай. 1998 елның 30 гыйнварында Россия президенты Борис Ельцин «Әниләр көне хакындагы» указга кул куя. Әлеге көнне канунлаштыруны сорап Россиянең, хатын-кызлар, гаилә һәм яшьләр эшләре буенча Дәүләт думасы Комитеты чыгыш ясый, төгәлрәге депутат, ЦК КПРФ әгъзасы Алевтина Апарина бу эштә активлык күрсәтә.*

*Әниләр көнен рәсмиләштерүнең максаты булып, хатын-кызга карата хөрмәт, гаилә нигезләрен ныгыту, кешеләр тормышында әни кеше нинди зур әһәмияткә ия икәнен искә төшерү, аналарның дәрәҗәсен күтәрү тора. Дөресен әйткәндә, элегрәк, совет заманында, энилэр коне беренче тапкыр 1988 елның 30 октябрендә Әзербайҗанның Баку шәһәрендәге 228 нче мәктәбендә билгеләнеп үтелгән.*







*Мәктәбебездә Әниләр көненә багышланган чаралар үтте. Бәйрәмгә әниләр, дәү әниләр, укытучылар, укучылар чакырылган иде. Укучылар концерт номерлары куйдылар. Шигырьләр, җырлар, биюләр аша иң газиз кешеләренә ярату, хөрмәт хисләрен җиткерделәр. Бу әниләр өчен чын бүләк булды.*



**4 ноябрь — Халыклар бердәмлеге көне.** Күпмилләтле халкыбыз — гасырлар дәвамында үзара татулык нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дөньяда тиңе булмаган зур куәт. 2005 елдан башлап билгеләнүче әлеге дата Русиянең яңа тарихында, бер яклап, Октябрь бәйрәмен алыштырды, икенчедән, дәүләтнең нигезен тәшкил итүче мөһим гомумкешелек кыйммәтләре тупланган иң олы бәйрәмнәрнең берсенә әверелде. Тарихи бергәлекне саклауда Татарстан Республикасының уңышлары, халыкара мәйданда аның абруе артуы илдәге татар тормышына да уңай тәэсир ясый. Киләчәктә дә төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы дуслык һәм татулык дәвамлы булсын.











***Без төрле, шул безнең байлык,***

***Без бергә, шул безнең көч!***

## *Кадерле милләттәшләр, хөрмәтле дуслар!*

***Барыгызны да Халыклар бердәмлеге көне белән тәбрик итәргә рөхсәт итегез. Әлеге көн – Россия дәүләтендә гомер кичерүче 190нан артык милләт вәкилләренең уртак бәйрәме. Халыклар бердәмлеге көне Ватаныбыз иминлеге өчен төрле диндәге, төрле милләт халыкларын берләштергән олы вакыйганың кайтавазы булып тора. Без Россиянең кайсы гына өлкәсендәге, республикасындагы шәһәр-авылларында яшәсәк тә, безне уртак максатлар берләштерә. Хәзерге шартларда без федерализм, демократия принципларына таянып, үзара ихтирам, тынычлык, иминлек һәм гаделлеккә тугры калып, Россия халыкларына хас булган бердәмлекне һәм гасырлар буена тупланган туганлык, кешелеклелек, дуслык хисләрен ныгытабыз.***


**БЕР БУЛЫП ТИПСЕН ЙӨРӘК!**

Йөз туксаннан артык милләт илдә!
Йөз туксан телдә сөйләшәбез...
Без - күп төрле! Бердәм булсак кына
Без көчлебез!.. Көчле - илебез!
Халыклар бердәмлеге - Бөек көч!
Яшәү нигезе ул зур Илнең!
Ил яшәсен, чәчәк атсын дисәк,
Бердәм булу шиксез шарт безнең!
Ике йөзгә якын милләт халкы -
Бербөтен булып яшәү кирәк!
Кемдер өлкән туган... Кемдер кече
Түгел!.. Бер булып типсен йөрәк!
Ил көчле булсын!.. Безнең теләк!






## Ял сәгатьләрендә













**Сәхифәне әзерләде:**
*педагог- психолог*
*Гыйбадуллина А.И*
***Корректорлар:** туган тел*
*һәм әдәбияты укытучылары*
*Садриева Н.З., Юнысова Р.К.*

*Редакция һәм*
*нәшриятның адресы:*
*422024, Татарстан*
*Республикасы, Арча*
*районы, Урта Курса*
*авылы, Яшьләр урамы,*
*11нче йорт*

**E- mail: Sskor.Ars@tatar.ru**